| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 13 августыннан № 16

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы тарафыннан 2019 елның 29 октябрендәге 29 нчы номерлы Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда федераль бюджетны үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020елның 01 апрелендәге 103-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1 Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының 2019 елның 29 октябрендәге 29 нчы номерлы «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет тезелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

54 статьяның 1 абзацы, 39 статьяның 3 абзацы, 58 статьяның 1 абзацы, 57 статьяның 3 пункты, 10 статьяның 2 абзацы, 39 статьяның 2 пункты, 13 статья, 15 статьяның 3 пункты 2021 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга;

34 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

34 статьяның 4 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

29 статьяның 2 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

34 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре генә, акцияләренең 100 проценты (өлешләре) җирлек милкендә булган муниципаль унитар предприятие, муниципаль унитар

предприятие тарафыннан гына тәэмин итәлергә мөмкин»;

34 статьяның 11 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан кененнән үз кечено керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат (pravo.tatarstan.ru) порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
"Ивановка авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе

А.П. Бодряева